**СОВЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

**РЕШЕНИЕ** — **КАРАР**

**28 апрель, 2023 ел** — **№ 287**

## «Биектау муниципаль районы бюджетына муниципаль унитар предприятиеләрнең салым түләгәннән һәм башка мәҗбүри түләүләрдән соң алар карамагында калган табышның бер өлешен күчерү тәртибе турында» нигезләмәне раслау хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 42, 62 статьялары, Россия Федерациясе Гражданнар кодексының 295 статьясы, «Дәүләт һәм муниципаль унитар предприятиеләр турында» 2002 елның 14 ноябрендәге 161-ФЗ номерлы Федераль законның 17 статьясы, «Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, муниципаль мөлкәттән файдалануның нәтиҗәлелеген арттыру максатларында, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. «Биектау муниципаль районы бюджетына муниципаль унитар предприятиеләрнең салым түләгәннән һәм башка мәҗбүри түләүләрдән соң алар карамагында калган табышның бер өлешен күчерү тәртибе турында» нигезләмәне (1 нче кушымта нигезендә) расларга.
2. Биектау муниципаль районы бюджетына күчерелергә тиешле муниципаль предприятиеләрнең табышының бер өлешен исәпләүнең дөреслеген һәм түләүнең вакытында булуын тикшереп торуны икътисадый үсеш, бюджет, салымнар һәм финанс мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.
3. Әлеге карарны Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы порталында http://pravo.tatarstan.ru урнаштырып бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Биектау муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе, җирле үзидарә һәм җәмәгатьчелек белән элемтә буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Совет рәисе,
муниципаль район Башлыгы — Р.Ф.Хисамутдинов

Татарстан Республикасы Биектау
муниципаль районы Советының
2023 елның 28 апрелендәге 287
номерлы карарына 1 нче кушымта

**Биектау муниципаль районы бюджетына муниципаль унитар предприятиеләрнең салым түләгәннән һәм башка мәҗбүри түләүләрдән соң алар карамагында калган табышның бер өлешен күчерү тәртибе турында нигезләмәләр**

1.Гомуми нигезләмәләр

1.1. Биектау муниципаль районы бюджетына муниципаль унитар предприятиеләрнең салым түләгәннән һәм башка мәҗбүри түләүләрдән соң алар карамагында калган табышның бер өлешен күчерү тәртибе турында нигезләмә (алга таба – Нигезләмә) муниципаль мөлкәттән файдалануның нәтиҗәлелеген күтәрү һәм бюджетка муниципаль унитар предприятиеләр табышының бер өлеше керүне тәэмин итү максатларында эшләнде.

1.2. Әлеге Нигезләмә муниципаль унитар предприятиеләр тарафыннан Биектау муниципаль районы бюджетына күчерелергә тиешле салым түләгәннән һәм башка мәҗбүри түләүләрдән соң табышның бер өлешен түләү күләмнәрен һәм срокларын билгели (алга таба - Табышның бер өлеше).

1.3. Табышның бер өлешен түләүчеләр дип, хуҗалык эшчәнлеге хокукында аларга беркетелгән мөлкәтләре Биектау муниципаль районының муниципаль милкендә булган муниципаль унитар предприятиеләр танылa.

1.4. Муниципаль унитар предприятиеләр кеременең бер өлеше кертеменнән Биектау муниципаль районы бюджеты кереме администраторы (алга таба - Бюджет) булып, «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» муниципаль казна учреждениесе тора.

2. Муниципаль унитар предприятиеләр табышы өлешенең күләмен билгеләү тәртибе

2.1. Муниципаль унитар предприятиеләр өчен табыш өлешенең түбәндәге күләмен билгеләргә:

1) 0 % – юкка чыгару, шул исәптән финанс савыктыруы яисә банкротлык стадиясендә стадиясендә булган муниципаль унитар предприятиеләр өчен.

2) 30 % - башка предприятиеләр өчен.

3.Хисаплылык

3.1. Хисап чоры булып календарь ел тора.

3.2. Түләү суммасын исәпләп чыгару буенча хисап предприятие тарафыннан салым органына еллык хисап бирелгәннән соң 10 көннән дә соңга калмыйча (предприятие кеременең бер өлеше кертемнәреннән җирле бюджет керемнәре администраторы булып торучы муниципаль берәмлек органына) тапшырыла.

3.3. Ел йомгаклары буенча Бюджетка табышның бер өлешен күчерү срогын - хисап чорыннан соңгы елның 01 августыннан да соңга калмыйча билгеләргә.

3.4. Бюджетка күчерелергә тиешле Табыш өлешен кертү срокларын бозган өчен салымнар һәм җыемнар турындагы федераль законнарда каралган күләмнәрдә пеня алу рәвешендә санкцияләр кулланыла.

3.5. Муниципаль унитар предприятиеләр җитәкчеләре предприятиеләрнең финанс-хуҗалык эшчәнлеге нәтиҗәләре турындагы мәгълүматларның дөреслеге, түләүләрне исәпләүнең дөреслеге һәм түләүләрнең вакытында түләнүе, исәп-хисаплылыкны тапшыру өчен шәхси җаваплы.